Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

“27” август 2019 ел № 129

“Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советының 2017 елның 19 апрелендәге 54 номерлы Карары белән расланган “Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлекләре территориясендә төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәреш кертергә:

31 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“Тышкы суүткәргечле түбәләрне, калынлыгы 30 см. дан артык булган кар катламы барлыкка килүгә юл куймыйча, периодлы рәвештә кардан чистартырга кирәк.”;

Кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлекле 35.14 пункты белән тулыландырырга:

“35.14. физик затлар һәм юридик затлар (шәхси эшмәкәрләр) тарафыннан үз милкендә яки файдаланууда булган җир кишәрлекләрендә балтырганны юк итү буенча чаралар үткәрергә.”;

Кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлекле 105.1 пункты белән тулыландырырга:

“105.1. Автовокзалда, пристаньда, базарларда, паркларда, бакчаларда, ял итү зоналарында, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният учреждениеләрендә һәм халык күпләп йөри торган башка урыннарда, урамнарда, торак йортларның подъездларында, тукталышларда, сәүдә объектларына керү юлында кимендә ике чүп савытлары куелырга тиеш. Чүп савытлары объектларның милекчеләре, арендаторлары тарафыннан билгеләнә. Чүп савытлары алар тулган саен йорт милекчеләре һәм территорияләрне арендалаучылар тарафыннан чистартыла. Чүп савытларын буяу кирәк булган саен башкарыла. Чүп савытларын чамадан тыш тутыру һәм пычрату рөхсәт ителми.”;

Кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлекле 115.2 пункты белән тулыландырырга:

“115.2. Юлның машиналар йөрү өлешендә механикалаштырылган җыештыру 2,5-3,0 см юл полотносы биеклегендә башланырга тиеш, бу исә яңа гына яуган карның 5см.ына туры килә. Механикалаштырылган җыештыру эшләре тәмамланганнан соң, юлның машиналар йөрү өлеше кардан һәм боздан тулысынча чистартылырга тиеш.

Урам һәм юллардан кар махсус әзерләнгән мәйданчыкларга чыгарылырга тиеш.”.

2. 2017 елның 8 сентябрендәге “Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советының 63 номерлы Карарының 1.32 пунктын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь урамы, 65 йорт ( АЖ администрациясе бинасы),

ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, 2 нче Октябрь урамы, 50 нче йорт (мәдәният йорты бинасы),

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге Карар рәсми игълан ителгән (басылып чыккан) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Тәмте авыл җирлеге Башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Тәмте авыл җирлеге Советы рәисе И. А. Зиновьев